РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 33 2024 елның 08 июле

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Шәңгәлче авыл җирлегенең генераль планын яңа редакциядә раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23, 24 нче статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошин тарафыннан 2020 елның 20 мартындагы 10-53/3621 номерлы килешенгән бәяләмәне исәпкә алып, 2024 елның 02 маендагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы:

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Шәңгәлче авыл җирлегенең генераль планын кушымта нигезендә яңа редакциядә әлеге карарда расларга.

2. Шәңгәлче авыл җирлеге Советына «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Шәңгәлче авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында» 2012 елның 23 октябрендәге 17 номерлы Шәңгәлче авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип тануны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Шәһәр төзелеше сәясәте һәм архитектура идарәсенә Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында расланган документны урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы Р.Х. Муллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН